РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

№ 41/2 Чистай шәһәре 6 февраль 2019 ел

Чистай муниципаль районы
Советының 18.07. 2018 елгы
“Ачык тыңлаулар (җәмәгать тикшерүләре)
оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы
Нигезләмәне раслау хакында”гы
35/5нче карарына үзгәрешләр
кертү турында

2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131нче Федераль закон нигезендә , Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Советының 18.07. 2018 елгы “Ачык тыңлаулар (җәмәгать тикшерүләре) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында”гы 35/5нче карары белән расланган ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4нче маддәнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“Ачык тыңлаулар халык, муниципаль берәмлек Советы (алга таба –Совет), муниципаль берәмлек башлыгы яки үз вәкаләтләрен контракт нигезендә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты җитәкчесе (алга таба – башкарма комитет җитәкчесе) инициативасы буенча уздырыла.”;

1.2 5нче маддәнең 1нче пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Муниципаль берәмлек башлыгы яки муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы белән уздырыла торган ачык тыңлаулар муниципаль берәмлек башлыгы карары белән билгеләнә.”;

1.3 9нчы маддәнең 2 нче пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Җирле бюджет проекты һәм җирле бюджетны үтәү турындагы отчет буенча ачык тыңлаулар муниципаль берәмлек башлыгы карары белән билгеләнә.”;

1.4 түбәндәге эчтәлектәге 15нче маддә белән тулыландырырга:

“15 нче маддә. Хуҗалык яки башка эшчәнлекне күздә тотып әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүне бәяләү буенча җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм уздыру үзенчәлекләре

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә хуҗалык яки башка эшчәнлекне күздә тотып әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүне бәяләү буенча җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм уздыру хуҗалык яки башка эшчәнлекне күздә тотып әйләнә-тирә мохитка тәэсир итүне бәяләүне көйләүче федераль закон үзенчәлекләрен исәпкә алып уздырыла.”

2. Чистай муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук Чистай муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлүенә контрольлек итүне Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль
районы башлыгы Д.А. Иванов